КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1375

2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында

Россия Федерациясе гражданнарының түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә конституциячел хокукларын тәэмин итү максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы турында» 2021 елның 28 декабрендәге 2505 номерлы карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2022 елда Программа кысаларында күрсәтелгән медицина хезмәтләре өчен исәп-хисапларны тәмамлау 2023 елның 15 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла;

Программаны тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә законнар нигезендә билгеләнгән тәртип һәм формалар нигезендә мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге эшчәнлек турында хисаплылык һәм Программаны раслаган көннән 14 көн эчендә – тиешле финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары кертелә;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

Татарстан Республикасының мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасы буенча медицина ярдәменә түләү турында тариф килешүе төзү буенча;

күбесенчә бер каналлы финанслауны тормышка ашыруга мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган

медицина ярдәме тарифларын һәм аларга түләү тәртибен әзерләү һәм вәкаләтле органга раслауга кертү буенча;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Программаны һәм медицина ярдәме өчен түләүгә билгеләнгән тарифларны рәсми сайтта урнаштыру буенча;

2022 елның 15 февраленә кадәр медицина оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге буенча килештерелгән планнарын «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә кертүне тәэмин итү буенча;

квалификация күтәрү программалары буенча хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазын сатып алу һәм ремонтлау чаралары планын билгеләнгән тәртиптә раслау буенча;

квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазын сатып алу һәм ремонтлау чаралары планына кертү өчен чараларны сайлап алу критерийларын раслау буенча.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы һәм «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарында әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Программаны гамәлгә ашыру чыгымнарын финанс белән тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

4. Яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) китереп чыгарган авыруларның таралу куркынычы барлыкка килү шартларында, Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы Президенты карары нигезендә яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуга бәйле рәвештә халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү буенча чикләү чаралары билгеләнгән көннән алып һәм аларны гамәлдән чыгарган көнгә кадәр иминият медицина оешмалары һәм мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы медицина оешмалары чыгымнарын финанс белән тәэмин итү, медицина ярдәме күрсәтү күләмнәренең фактта үтәлешен исәпкә алмыйча, мәҗбүри медицина иминияте территориаль программасын эшләү комиссиясенең карары белән бүленгән мәҗбүри медицина иминияте буенча медицина ярдәме күрсәтүнеңербөтен уникедән ун еллык финанс белән тәэмин итү күләменә кадәр медицина ярдәменә түләүне ай саен авансла тәртибендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

5. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин